**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АНДРЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АНДРЕЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Андреевка ав. **БОЕРЫК**

«22» август 2025 ел № 134

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге территориясендә терекөмешле кулланылган лампаларны туплау урыннары турында" 2023 елның 21 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары нигезендә «Яктырткыч җайланмалар, электр лампалары, тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау өлешендә һәм аларны урнаштыру гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булганда җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында (2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карар белщн кертелгән үзгәрешләр белән)», Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге территориясендә терекөмешле кулланылган лампаларны туплау урыннары турында» 2023 елның 21 мартындагы 3 номерлы карарының 2 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка территориясендә, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында (стойкаларда) урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә, шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Андреевка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга..

Җитәкче Н.И. Егорова